**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**«Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм файдалану концепциясен гамәлгә ашыру буенча ведомствоара координация советы составына үзгәрешләр кертү турында**

Аерым затларның башка эшкә күчүе һәм вазыйфалар атамалары үзгәрү белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм файдалану концепциясе турында» 2012 елның 9 октябрендәге ПУ-862 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 22 июнендәге ПУ-570 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган «Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм файдалану концепциясен гамәлгә ашыру буенча ведомствоара координация советы (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан Р.Х. Миңнегалиевны, И.Ш. Халиковны чыгарырга;

б) Совет составына түбәндәгеләрне кертергә:

Гәрәев Зөфәр Фәнил улын – «АК БАРС» акционер коммерция банкы (гавами акционер җәмгыяте) идарәсе рәисен (килешү буенча);

Песошин Алексей Валерьевичны – Татарстан Республикасы Премьер-министрын, аны Совет рәисе итеп расларга;

в) Совет әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Ш.Р. Агеевның – «Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы рәисе (килешү буенча)»;

А.Т. Әйделдиновның – «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы директоры (килешү буенча)»;

А.П. Лаврентьевның – «Татарстан Республикасы Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (төбәк эш бирүчеләр берләшмәсе) президенты (килешү буенча)»;

Н.Ө. Мәгановның – «В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча)»;

Я.Г. Муравьевның – «Татарстан Республикасы «Киләчәк факторы» яшьләр инициативаларына ярдәм итү төбәк иҗтимагый фонды директоры, «Штаб» креатив индустрияләр резиденциясен оештыручы (килешү буенча)»;

Т.Җ. Сөләймановның – «Сәләт» Татарстан республика яшьләр иҗтимагый фонды башкарма директоры (килешү буенча)»;

С.В. Юшконың – «Казан милли тикшеренү технологик университеты ректоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 01 июль
№ ПУ-596